ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» гыйнвар 2020ел № 07

Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 30 апрелендәге 168 номерлы «Әгерҗе районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында»гы карары белән расланган Әгерҗе районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексыныц 195.3 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенец 2016 елның 27 июнендәге 584 номерлы «Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары, дәүләт яки муниципаль учреждениеләр, дәүләт яки муниципаль унитар предприятиеләр, шулай ук дәүләт корпорацияләре, дәүләт компанияләре һәм хуҗалык җәмгыятьләре тарафыннан куллану өчен мәҗбүри булган таләпләр өлешендә һөнәри стандартларны куллану үзенчәлекләре турында» карары нигезендә, РФ Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының ««Бухгалтер» һөнәри стандартын раслау турында» 2009 елның 21 февралендәге 103н номерлы боерыгы нигезендә, РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының ««Мәгълүмати-коммуникацион системаларның система администраторы» һонәри стандартын раслау турында» 2015 елның 5 октябрендәге 684н номерлы боерыгы нигезендә, РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының ««Персонал белән идарә итү буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2015 елның 06 ктябрендәге 691н номерлы боерыгы нигезендә, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәм социаль гарантияләрне тәэмин итеп, Әгерҗе муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренең хезмәт хакын тәртипкә салу максатыннан, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 30 апрелендәге 168 номерлы «Әгерҗе районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында»гы карары

белән расланган Әгерҗе районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пункт өченче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен вазыйфаи оклад (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль учреждение директоры | 23700 |
| Муниципаль учреждение директоры урынбасары | 21500 |
| Бүлек башлыгы | 17700 |
| I категорияле бухгалтер | 15300 |
| Бухгалтер | 14000 |
| Белгеч | 14000 |
| Система администраторы | 15300 |

1.2. 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«4) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә ай саен акчалата бүләкләү, хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды кысаларында матди ярдәм;»

1.3. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды кысаларында эш нәтиҗәләре буенча ай саен түбәндәге күләмнәрдә премияләр:

Бухгалтер -1%

I категорияле бухгалтер– 4%

Бүлек башлыгы – 7%

Директор урынбасары – 7%

Директор – 10%»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Баженовага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**